| | |
|---|---|
| **ГЛАВА<br>СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ИСКЕ ШӘЙМОРЗА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

с.Старое Шаймурзино

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 18 ноябре № 20

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Иске Шәйморза
авыл җирлегенең Кече Шәйморза торак
пунктында үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә белән расланган Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының 07.10.2019 ел, № 51/1 карары (15.11.2019 ел, №53/5 редакциясендә) КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Иске Шәйморза торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 3 декабренә 9:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Кече Шәйморза авылы, 40 лет Победа урамы, 40 йорт, Кече Шәйморза мәдәният йорты.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Кече Шәйморза авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме?:

- Кече Шәйморза авылы зиратынын коймасын тотарга

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы: И.Д.Мөхитова